СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*8 август, 1998 ел.*
*ШИМБӘ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 90 (8247)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# Уҗым чәчәр чак җитте

## “Уңыш - 98” матбугат үзәге хәбәр итә

**Өч көн элек кенә игенчене сөендереп явып үткән яңгырлар уҗым чәчү кебек гаять мөһим эшкә тотынырга җай чыгуын искәртте. Хафизов исемендәге, “Комбайн” һәм кайбер башка хуҗалыкларда яшел азыкка дигән мәйданнарда ул эшне башладылар да инде. Байтак кына хуҗалыкларда уҗым чәчеләсе мәйданнарның әзере планлаштырылганга якын, шикәр заводы һәм “Агрохимсервис” ярдәмче хуҗалыкларында бу максатларда туфрак эшкәртелеп бетте, “Таң”да да күп эш калмады. Башка хуҗалыкларда да ашыгырга кирәк.**

**Бер үк вакытта күпчелек хуҗалыкларда туңга сөрү эшенә дә керештеләр. Кичәге көнгә “Киекле”дә 350, “Татарстан”да 250, Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, Мичурин исемендәге һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында 200әр гектар җир эшкәртелде , “Дуслык”та да бу эш уңышлы бара.**

**Шулай да әле төп бурыч булып игеннең быелгысын җыеп алу кала. Хуҗалыкларның абсолют күпчелегендә сабан ашлыгын җыюга керештеләр . Синдряков исемендәге, “Комбайн”, “Рассвет”, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында игене җыеп алынган сабан ашлыгы кырлары шактый гына. Суктырылган мәйданнарның яртысыннан артыгы - борчак. Хафизовлылардан тыш,”Кондырча”, “Тәрнәс”, “Киекле”. Мичурин исемендәге, “Комбайн” һәм “Чулпан” хуҗалыкларында сабан бодаен да суктыралар. Борчак әлегә “Кондырча”, “Рассвет”, “Сөлчә”, Мичурин исемендәге һәм Хафизов исемендәге хуҗалыкларда әйбәт кенә чыга. Кондырчалылар һәм мичуринлылар сабан бодае буенча да алдырырга чамалыйлар. Соңгыларында һәм “Сөлчә”дә солы уңышы да яхшы.**

**Терлек азыгы хәзерләү темпын ишәйткән хуҗалыклар да аз түгел. “Дуслык”та, “Заря”да сенаж запасы ихтыяждан артык инде. “Рассвет”, Синдряков исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, “Родина”, “Чулпан”, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында соңгы өч - дүрт көндә сенаж салу темпы чагыштырмача югары булды. Ә менә “Заветы Ильича”, “Сөлчә”, “Игенче”, Кузнецов исемендәге, Хафизов исемендәге, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында бер шартлы терлеккә хәзерләнгән азык берәмлеге 4,5 - 6,7 центнер гына әле.**

## Урак батырсыз узмас

**Мичурин** исемендәге хуҗалыктан **Константин Аркадьевич РОМАНОВ** "Нива" комбайны белән 16 гектарда борчак чабып смена нормасын 219 процентка үтәде.

***

**Сөт - май комбинаты** ярдәмче хуҗалыгыннан **Андрей Анатольевич СВЕТКИН** "Дон - 1500" белән ашлык суктыруда нормасын шул кадәргә үк арттырып башкара.

***

**"Сөлчә"**дән **Валентин Рудольфович САНДРЮХИН** К - 700 тракторы белән 110,**"Тәрнәс"**тән **Вячеслав Анатольевич ХРИСТОФОРОВ** 130,**"Таң"**нан **Әхтәм Якуб улы БИЛЬДАНОВ** ДТ - 75 тракторы белән 70 гектарда туңга сөрделәр инде.



*Техникага, игенчелек эшенә мәхәббәт Сергейга әтисе Арсентий Николаевичтан күчкәндер, мөгаен. Әтисе озак еллар комбайнчы булып эшләде, иген икте, ашлык суктырды. Хәзер инде игенчелек язмышын Сергей Арсентьевич дәвам итә. Ул ДТ - 75 тракторы белән җирләр әзерли, чәчүдә катнаша. Хәзер ул нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында Иван Васильевич Григорьев звеносында хезмәт куя. Бу көннәрдә Алексашкин азык әзерләү звеносында эшли, җәмәгать маллары өчен кышкылыкка мул запас әзерләү мәшәкате белән яна.*

***Рәсемдә: нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы тракторчысы С.А.Алексашкин.***

***Н. АЗИЗОВ фотосы.***

## ТЕПМ АРТА

Рифкать Нурмөхәммәтович Сәгыйровның СК - 5 комбайны азык әзерләү чорына ук кырга чыккан иде инде. Комбайнга асылган ЖРБсы белән әүвәл ул берьеллык үләннәрне печәнгә чаптырды, аннан бөртекле культураларга күчте. Хәзер комбайнчы солыны теземнәргә салуда эшли, аның исәбендә - урак башыннан 130 гектар урылган мәйдан исәпләнә инде. Ә менә игеннәрне суктыруга “Дон - 1500” комбайнчысы Айдар Вәлиярович Билданов әйбәт кенә керешеп китте. Былтыр да ашлык җыюда югары күрсәткечләргә ирешкән игенченең хезмәткә мөнәсәбәте сокланырлык. Ярдәмчесе Дамир Заһретдинов белән борчак суктыруда эшлиләр алар, югалтуларга да, тик торуларга да юл куймыйлар.

Шулай, “Киекле” дә сабан культураларын җыю әйбәт темп алып килә.

**А.ДАУТОВА,**
**экономист.**

## ЯЛ ИТӘРГӘ КИТТЕЛӘР

Шушы көннәрдә генә социаль тәэминат министрлыгы линиясе буенча районнан 9 бала Крутушка легерена ял итәргә киттеләр.

Путевкалар күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләр өчен күздә тотылган, шунлыктан - бушлай. Балалар 21 көн дәвамында бирәдә ял итәчәкләр, көч җыячаклар.

## Туберкулез җиңмәсен дип

Соңгы елларда туберкулез белән авыру җәһәтеннән эпидемиологик хәл шактый катлауланды. Әйтик, бу чирнең актив формалары белән авыру 1998 елда 1996 елдагы белән чагыштырганда 1,7 тапкыр артты. Ә шул ук вакытта 20 меңләп өлкән кеше инде ике һәм аннан да күбрәк ел флюорографик карау үтмәгән. Һәм бу эштә район табиблары һәм халкына ярдәмгә тиздән Казаннан флюорограф киләчәк. Районда профкараулар 11нче августтан 20нче октябрьгә кадәр узар дип күздә тотыла. Район һәм шәһәр хакимияте башлыгының “Нурлат районы халкын флюорографик карау үткәрү турында” күптән түгел чыгарган карарында да нәкъ шушы сроклар әйтелә.

Хуҗалык җитәкчеләре, җирле үзидарә Советлары рәисләре медицина хезмәткәрләре белән берлектә бар халыкның профкарау үтүен оештырырга тиешләр. Ул эш район үзәк сырхауханәсе тарафыннан төзелгән төгәл график буенча барачак.

*Иртәгә - Төзүчеләр көне*

## Бәйрәмегез белән, яңаны коручылар!

*Нинди генә заманнар килсә дә, алар хезмәтенә ихтыяҗ бетми торган һөнәрләр бар. Төзүче профессиясе - шуларның берсе. Менә бүген дә, базар икътисады, финанс кытлыгы һәм башкалар дип күпме генә зарлансак та, Нурлатыбызның һәм авылларның йөзен бизәп, эшләүче халыкка уңайлыклар китереп берсеннән - берсе матуррак йортлар калка, без теләгәннән акрынрак темпларда булса да социаль - көнкүреш объектлары салына. Быелның алты аенда гына да районда 4600 квадрат метрдан күбрәк торак мәйданы файдалануга бирелде һәм бу узган елның шул чорындагыдан өч (!) тапкырга диярлек күбрәк. Иң беренче чиратта Сез - төзүчеләрнең фидакарьләрчә тырышып эшләвенең күркәм нәтиҗәсе бу. Ярты елда 80 миллин ярым сумнан күбрәк капитал салу үзләштергән төзүчеләребезнең хезмәте промышленность объектлары төзү һәм реконструкцияләүдә, быел аеруча киң колач белән бара торган газлаштыруда, башка төр эшләрдә дә бәяләп бетергесез дәрәҗәдә зур. Төзүчеләребез авыл җирләрендә дә киң масштаблы эшләр алып баралар, юл төзелешендә билгеләнгән графикны уңышлы үтиләр. Иң куандырганы - төзүче һөнәрен гомерлеккә юлдаш иткән дистәләрчә, йөзләрчә осталар шушы эшне бар күңелләрен биреп, хезмәтләре кешеләрне куандырып торырлык иттереп башкаралар. Акча юклык тынны кыскан шушы авыр заманда да Сезгә йөкләнгән изге миссиягә тугърылык саклап намус белән эшләүче барлык төзүчеләргә ихлас рәхмәтебезне җиткерәбез, барчагызга да тазалык - тынычлык, гаиләләрегезгә иминлек, бәхет телибез.*

***Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН,***
***халык депутатларының***
***берләштерелгән Советы рәисе,***
***район һәм шәһәр хакимияте башлыгы.***

## ЭЛЕККЕГЕ ДАН КАЙТЫР ДИБЕЗ

**Хуҗалыкара төзелеш оешмасы - райондагы тердәшләре арасында иң зурлардан һәм бу ясалма әрелек кенә түгел: 1987 елда МСО составына кертелгән 547 нче ПМК районда иң абруйлы төзелеш оешмаларыннан, нигездә авыл җирендә төзелеш алып барган “Татколхозстрой” ПМКсының да эше гаять колачлы иде. Аңарчы Казанга буйсынган төзелеш механизмнары, Чистайга караган автотранспорт һәм измә- бетон узелын да кушкач, гаять киң масштаблы төзелеш оешмасы килеп чыкты. Шул чакта ук оешманың анык кына структурасы билгеләнде һәм ул җайлы гына эшләп тә китте.**

**Тик менә заманаларның катлаулануы шундый эре оешманың эшен сизелерлек аксатты: үзәкләштерелгән тәртиптә матди - техник тәэмин ителешнең бетүе, заказчыларның яңа төзелешләргә тотыну өчен түгел, хәтта элек эшләткән эшләренә дә түләргә мөмкинлекләре калмау, шуның белән бергә киң масштаблы оешманың эшен оештыруның катлаулануы, социаль сфераны аягында тоту өчен сорала торган чыгымнарның күзгә күренеп арта баруы һәм башка сәбәпләр МСО кебек абруйлы оешманың да элекке данын шактый тоныкландырды. Дөрес, моңа карап кына оешма тукталып калмады, структур һәм башка үзгәрешләр аша базар шартларында яшәү җаен эзләүдә булды һәм ул эзләнү әле бүген дә дәвам итә. МСО һәм аның составындагы 547нче ПМК начальнигы Р.М.КАРАМА белән әңгәмәбезне дә шул хакта сөйләшүдән башладык.**

***- Рөстәм Мингалиевич, быел гына МСО дүрт ярыммөстәкыйль оешмага аерылган иде. Инде менә тагын нииндидер берләштерүләр турында сүз йөри...***

- Ике ПМКны, төзелеш материаллары комбинатын һәм кирпеч заводын аеру дөрес булмады димәс идем мин. Иң әүвәл, элек бер кеше тарафыннан бүленә торган техника аларның үз карамакларына бирелде, ә бу теге яки бу оешма җитәкчесенә эшен үзе теләгәнчә, мөмкинлекләренә карап планлаштырырга җай бирә. Мөстәкыйльлек ягыннан башка уңайлыклары да бар бүленүнең. Мисал өчен, кирпеч заводы хәзер, сан артыннан бик үк кумыйча, продукциянең сыйфатына игътибарны арттырды һәм Каравыл Тавы кирпеченә сорау да зур хәзер. Әмма мөстәкыйльлек белән генә эш бетми шул әле - акчаң булмаса, үзем - баш та, үзем - түш дип кенә әллә ни сикерә алмыйсың. Әйтик, шул ук төзелеш материаллары комбинаты элек нигездә ПМКлар заказы буенча эшли, кирәкле чималын табыштыру да нигездә баш идарә җитәкчелеге өстендә иде. Ә хәзер ПМКларның комбинаттан ала торган материаллар өчен вакытында түләргә мөмкинлеге юк. Заказ булмагач, коллектив эшсез тора, эшләмәгәч акча керми... Анары, теге яки бу оешманы бүлгәләүне административ юл белән генә башкару бик үк дөрес тә түгелдер, чөнки, беренчедән, оешманың нигезен тәшкил итүче матди-техник база күмәк милек булып тора, икенчедән, шушы оешмаларга гомерләрен багышлаган йөзләрчә кешенең өлешен юкка чыгарып, фикеренә колак салмыйча да булмый торгандыр. Шуңа да район хакимияте башлыгы безнең элеккеге МСО базасында кайчандыр булган 547 нче һәм "Татколхозстрой" ПМКсы кебегрәк ике оешма төзү турындагы тәкъдимебез белән килеште.

**( Ахыры 2 нче биттә).**

# ЙОРТЛАР КАЛКА СЕЗНЕҢ ХЕЗМӘТ БЕЛӘН, СЕЗ ДӘ КУАНЫГЫЗ КУЛЫГЫЗДАН

## ЭЛЕККЕГЕ ДАН КАЙТЫР ДИБЕЗ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә).*

***- Димәк, оешма эшчеләренең соңгы елларда элеккеге, аерым - аерым яшәгән заманнарны еш искә алуы юкка түгел иде?..***

- Сүз дә юк, җыйнаграк оешма белән җитәкчелек итүе дә, эш оештыру, матди - техник тәэминат ягын кайгырту да җиңелрәк. Заманында безнеке кебек үк эреләндерелгән оешмалар башка районнарда туксанынчы еллар башында ук аерылдылар бит инде. Сез хаклы - эшчеләребез авызыннан: " Ничек инде ул, үз кулларыбыз белән төзегән кирпеч һәм төзелеш материаллары заводларыннан материалны үзебез үк сатып алырга тиешбез?" дигәнне еш ишетергә туры килә. Заманында аларны коруга күпме матди байлык тотылды, күпме акча салынды, күпме кешенең хезмәте керде бит...

***- Хәзерге ниятегез барып чыкса, эш егез ничек тә уңайга китәр дип ышанасы килә. Ә элеккеге бурычлар һәркемнеке үзендә кала бит...***

- Хезмәт хакы буенча бурычларга килсәк, аларны быел гына да иске акча белән 1 миллиард 300 миллион сумга, ягъни яртылаш киметтек. Сүз дә юк, хезмәт хакы түләү эше җиңел түгел, ай саен авanслаудан котыла алганыбыз юк әле. Менә төзүчеләр көненә тагын шактый гына аванс өләшергә җыенабыз...

***- Димәк, оешма барыбер эшләп тора?...***

- Анысы күз алдыгызда бит. МСОны ничек кенә яманларга тырышмасыннар, Нурлатта шактый ук күзгә ташланырлык объектларны безнең төзүчеләр кора бит әле. Былтыр аэропорт бинасын рекордлы срокларда өлгерттек - ташчыларыбызның да, сылаучы - бизәүчеләребезнең дә эше көлеп тора. Хәзер менә сәнгать мәктәбендә эшне тәгәлләп киләбез. Болар икесе дә - район җитәкчелегенең зур игътибар үзәгендә булган объектлар. Контроль булганга гына шулай сыйфатлы эшлиләр дип уйламагыз, тиешле финанслау һәм матди тәэмин ителеш булгач, эшчеләребезнең дә күңеле үсә, безгә дә эшне оештыру җиңелрәк. Әле менә шушы сәнгать мәктәбендә генә дә еллык финанслау лимиты чикләнгәч беразга эшне туктатып торырга мәҗбүр булган идек. Ә быел балта осталары һәм сылаучы - бизәүчеләр рекордлы срокларда һәм яхшы сыйфат белән никадәр эш башкардылар.

***- Анысы шулай, әле кыш көне генә бинаның эче шулкадәр шыксыз, эш күләме шулкадәр күп иде, ә хәзер анда керсәң чыгасың килмәслек. Ни генә димәсеннәр, 547 нче ПМК кызлары элеккеге маркаларын саклыйлар.***

- Маркаларын гына түгел, ПМКның үзен дә саклыйлар дияр идем әле мин аларны. Ничек кенә авыр булмасын, шушында гомер буе эшләгән сылаучы - бизәүчеләребезнең соңгы елларда берсе дә эштән китмәде бит. Тамара Ишкальдина, Елизавета Романова, Зинаида Шәрәфетдинова һәм Римма Туишева бригада һәм звенолары иң тотрыклы коллективлардан. Равил Мусин һәм Әнәс Сабировның ташчылары, Рөстәм Хәсәншин белән Тәлгать Шәйдуллинның монтажчылары һәм балта осталары - бүгенге көндә безнең ныклы таяныч. Төзелеш материаллары комбинатында, кирпеч заводында продукция сыйфатлы икән, монда Рәзинә Низамиева, Галина Матросова кебек дозалаучыларның, Марат Фәйзуллин, Любовь Клементьева җитәкчелегендәге формалаучыларның, цемент складры слесаре Камил Сатдаров, яндыручылар Михаил Имуков һәм Александр Рыбаков кебекләрнең лаеклы өлеше бар...



***Тиздән сәнгать мәктәбе бусагасын атлап керүчеләр Галина Леонидовна Овчинникова белән Тамара Васильевна Волкова җәйгән мәрмәр баскычларга басып менәчәкләр.***

\- \- \- \- \- \- \- \-

***Зинаида Яковлевна Шәрәфетдинова бригадасы кызлары бу көннәрдә Кизләү мәктәбе һәм мәшыгульлек бюросы биналары төзелешләрендә эшлиләр.***



***- Мактау сүзе белән тамак туймаганы билгеле, акчасы булмаса, мактаудан күңел дә булмыйдыр хәзер. Эшчеләрегезгә очын -очка ялгап барырлык итеп кенә булса да хезмәт хакы биреп бару өчен мөмкинлекләрегез нинди соң?***

- Инде әйткәнемчә, район җитәкчелеге безне "акчалы" заказларсыз тотмый әлегә. Хәзерге вакытта зур көчне Төрнәс спирт заводында котельня төзелешендә тотабыз. Хезмәт һәм мәшгульлек бюросының матур гына булып күтәрелгән бинасы да - безнең егетләр эше. Чистарту корылмаларын да төзеп бетерәсе бар, СПТУ микрорайонында ике йортны да озакка сузмыйсы иде...

***- Анысы үзегездән тора торгандыр бит?***

- Алай гына булса бер хәл иде дә бит. Әйтик, 33 фатирлы йортта 1,2, акушерлык пунктында 1,5 миллиард сумлык эшебез өчен түләнмәгән, СПТУның үзендә былтыр эшләгән эшнең миллиардтан артык акчасы һаман да алмаган. Ә инде берничә ел буе агропромышленность комплексында җыелган алачакларыбызны кабатлап торасы да килми хәтта.

***- Ә чыгымнарны барыбер тотасы инде...***

- Ничек кенә әле. Төзелешкә турыдан туры бәйле булмаган чыгымнарыбыз бихисап зур бит безнең. Район җитәкчелегенә рәхмәт, торак фондын муниципаль милеккә күчерү безне күпме мәшәкатьтән дә, чыгымнардан да азат итте. Хакимият башлыгы еллык чыгымнары 600 миллион сумга җыела торган балалар бакчабызны да җирле Совет карамагына бирү турындагы үтенечебезгә колак салды. Безнең котельнядан җылытылган тулы бер бистәгә газ кертелү никадәр җиңеллек китерде безгә. Инде котельняның үзен дә шәһәр җылылык челтәре карамагына тапшыра алсак...

***- Аннан ары да эшегез уңайга китмәсә, акланырга, зарланырга сәбәбегез дә калмый инде аннары, Рөстәм Мингалиевич...***

- Эшләргә теләмәгән кеше генә сәбәп эзли диләр бит, ә безнең эшләргә теләгебез зур. Структур үзгәрешләр *экспериментын да кызык өчен үткәрүебез түгел бит, ә ничек тә эшне алга җибәрү ниятеннән.*

***- Шулай гына була күрсен иде инде. Заманында ярты Нурлатны төзегән, колхозлардагы барлык эре корылмаларга куллары тигән төзелеш оешмаларының элеккеге даннары яңадан кайтсын иде.***

**Әңгәмәдәш Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

**Н. АЗИЗОВ фотолары.**

## АЛАРНЫ ХЕЗМӘТ ДУСЛАШТЫРДЫ

Аларга эштә шулай матур күлмәк, үкчәле туфлиләрне салып куярга туры килә. Кызлар күбрәк чалбар, уңайлы кофта киеп эшләргә тырышалар. Шулай җайлырак бизәүче - сылаучыларга көненә берничә мәртәбә "кәҗәгә" үрмәләргә, стенаның бик биек сызыгына үрелергә яки бөтенләй дә башыңны артка ташлап түбә агартырга- тигезләргә туры килгәндә, я булмаса үрмәләп плинтуслар буяганда киемнең матурдан бигрәк уңайлырагы кулайрак шул. Инде эш тәмамлангач, киемнәрен алмаштыргач, әле шул арада кечкенә көзгегә карап хатын - кыз гадәте буенча йөзләренә бер - ике кирәкле "штрих" та өстәгәч һәм мут кына елмаеп та җибәргәч - бизәүчеләр әле генә янәшәдә измә буяу арасында йөргән иптәшләренә үзләре дә беренче күргәндәй сокланып куялар.

Ә бу хис һәрчак кешене сөендерә! Фәлән ел бергә эшләү дәверендә бер - берләренә тупасланмаганнар, гаҗәпләндерүдән бизмәгәннәр икән - димәк, эшләрендә дә эзләнүдән, иҗат итүдән, матурлыкны бәяләүдән туктамаганнар булып чыга бит.

Кызлар шулай эшлиләр дә. Бер бригада булып эшләүләренә 5 - 6 ел аларның.Кайчандыр шактый күләмле "Нурлатнефть" НГДУсы торак - коммуналь хуҗалыгы бизәүчеләренә төзелешләрдә эшләргә дә, нефть объектларына, торак фондка ремонт ясарга да туры килә иде. Соңгы үзгәрешләр нәтиҗәсендә алар җыйнак кына бүлекчәдә ремонт бригадасы булып калдылар. Юлия Васильевна Ильина (сулда) җитәкчелегендәге бу төркем торак йортларга, учреждение биналарына, производство объектларына, конторaларга ремонт ясый. Кызлар һәр ремонтны кушылган белән чикләнмичә, күңелләре һәм фантазияләре җиткәнчә, үз җаннарына ятканча бизәп, җиренә җиткереп эшләргә гадәтләнгәннәр. Бусы - нигездә бригадир Юлия Васильевнаның хыялыйлыгына бәйле. Белгечлеге буенча мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбиячесе Юлиядә гаҗәеп мул һәм бай ул күңел бизәге. Бар яктан да булдыклы, кул эшләренә оста, бизәргә - матурларга дигәндә бар дөньясын онытучы Ильина идеясын хезмәттәшләренә дә йоктырып, үзе күзаллаган манзарага ирешкәнче эзләндерә, эшләтә



белә. Ә Наилә Исмәгыйловна Нәбиева (уңда) белән Галина Лотфрахмановна Левакова (уртада) иренә торганнардан түгел. Наилә шул хезмәткә 15 ел гомерен биргән кеше. Ә Галя - һөнәре буенча техникумда алган белемен шулай ук 6 ел инде практикада чарлый. Кызлар бер гаилә кебек яшиләр,хезмәт бүлешмичә эшлиләр. Ә кемнең нәрсәдә көчле булуын үзләре бик әйбәт белгәнлектән, күбрәк шул хезмәтне йөкләргә тырышалар. Әйтик, Юлия - плитә ябыштыру остасы булса, Наилә - бик уңган штукатур, Галя - буяу - отделкаларны җитез башкара. Шулай килешеп эшләгәч, уртак эшнең нәтиҗәсе дә һәрчак сөенечле була: кызлар башкарган эш көлеп тора,хуҗалар канәгать кала.

Әлбәттә, өч хатын - кыз янәшә эшли икән, аларның бар сере, бар сүзе шулай ук уртага салып сөйләнелә. Аннары, хатын - кызлар язмышында бигрәк күп шул уртаклыклар! Өчесе дә әниләр - Юлия - берүзе 2 баласын институтта укыта. Наиләнең олы кызы да югары белем ала, янындагы икесе дә бүген - иртәгә һөнәр эзләр яшькә җитеп киләләр. Галяның да өч бәләкәче, тик алар әле кечкенәләр. Шул өч бәләкәче, ире белән аз гаиләлеләр өчен фатирда яшәп ята төзүче хатын...Балалар мәшәкате бер якынайтса кызларны, көнкүреш, йорт темасы янә дә бергә бәйли. Бу яктан да аларның һәркайсы үзенчә сәләтле. Юлия бизәргә, комфорт тудырырга оста булса, Наилә - аш - су тирәсендә тәҗрибәле пешекчеләреңне дә уздырырлык. Инде эштән куллары алҗыган, тормыштан күңелләре тулган чакта кызларга күңел күтәрергә җыр булыша. Юлия Васильевна нәфис, моңлы тавыш белән җыр суза, аңа Галина кушыла да, шул моң дулкынында бар күңел юшкыннары эрегәндәй була... Измә, келәй, буяу исе аңкыган, әле тәртип салырга өлгермәгән соры бина да авыр, кул башларын алҗыта торган эш урыны түгел, ә менә бүген - иртәгә алар хезмәтеннән көлеп торасы кунак өе буласын сиздереп, сөенеч, яктылык белән тулгандай итә. Ахыр чиктә, аларның үзләрен дә шул хезмәт - шул яңартасы биналар, бизисе йортлар, буйыйсы бүлмәләр табыштырды һәм дуслаштырды бит!

Төзүченең шундый бәхетле мизгелләре бар: ул кеше сөенечен күрә. Шул үзе тудырган сөенеч хакына куллары сызлавын да, аяклар авыртуын да, үтәли җилне дә, буяу исен дә аңлап, зарланмыйча кичерә һәм хуҗалардан да артык шатлана, горурлана. Ильина бригадасы кызлары да ул минутларны күп татыдылар. Әле тагын күпме кичерерләр. Кешеләр елдан - ел матуррак яшәргә, зәвыклырак йорт булдырырга тырышалар бит. Ә ул матурлыкны нәкъ менә буяучы - бизәүче кызлар гап - гади Юлия, Наилә, Галина кебек уңганнар иҗат итә .

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# ТУКСАН СИГЕЗНЕҢ ЭССЕ ҖӘЕ



Кызу көннәрнең өченче ае китте инде. Һәр кичне, синоптикларның хәбәрләрен тыңлаган саен, бәлки алар бу юлы ялгышырлар дип өметләнәбез. Тик, юкка. Көн туугa, тагын кояш рәхимсез кыздыра башлый. Җитмәсә, Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә - тирә мохитне күзәтү үзәге кайсы елларда әле августта иң кызу көннәр булганлыгын да искә төшерә. 1920нче елда, мәсәлән, Казанда 38, Алабугада 39 градуска җиткән. Димәк, чыдарга кирәк әле.

Эсселек халыкны су буена куа. Ванна, салкын душ белән генә котылып булмый, кеше Кондырча, Чирмешәнгә агыла, хәленнән килгәннәр диңгез буена ук китеп бара. Менә быел дистәләгән нурлатлылар гаиләләре белән Краснодар краена, Урта диңгез пляжларына юл алдылар. "Ничек ял иттегез?" дигән сорауга елмаеп кына куялар. Ә җәйгә монда калучылар нефтьчеләрнең кайчандыр гөрләп торган бассейнын искә төшерәләр. Хәзер ул ташландык хәлдә. Чирмешән буенда исә гаилә белән ял итәргә чыгучылар ташлап калдырган чүп - чар, савыт - сабаның чуты юк.

Бу кызу халыкның кәефендә ничек чагыла соң? Мисал өчен, 2нче августта термометр тышта 35 градус эсселек икәнлеген күрсәтә иде. Ә сырхауханәнең УАЗигында исә тагын да зур. Ашыгыч ярдәм машинасы бу көнне 52 тапкыр юлга чыкты. 8 сырхауның температурасы күтәрелгән. Үтәли җилдән, туңдырманы чамасыз күп ашаудан, суыткычтан алып су эчүдән икән. 14 кеше йөрәк - кан тамыры системасы, 5се бронх астмасы көчәюдән чакырган, берсенә бөер синдромлы геммарагик бизгәк диагнозы куелган. (Шәхси гигиена кагыйдәләрен һәрвакытта да үтәргә кирәк шул!).

Янгыннарга килгәндә бу кызу ике айда Нурлат янгын частена 50 хәбәр кергән. 13 урында чүп - чар, 12 мунча һәм гараж, 5 йорт януы теркәлгән. Ут чыгуга еш кына мунча якканда ваемсызлык, эретеп ябыштыру эшләре вакытында, көнкүреш электр приборларыннан файдаланганда кагыйдәләрне санга сукмау сәбәп булып тора. Россиядә урманнарда 17 мең янгын чыкса да, бездә, шөкер, ул яктан тыныч әле.

Эсседә эшләргә мәҗбүр булган халыкка бигрәк тә авыр. Иң кыены комбайнчыларга, төзүчеләргә, нефтьчеләргә, юл салучыларга, башка кайбер һөнәр ияләренә һәм... кухняда мәш килеп ризык әзерләп һәм тузлап - нитеп ятучы хуҗабикәләргә.

Билгеле инде, бу көннәрдә туңдырмадан да популяр товар юк. Нурлатка аны Яр Чаллыдан да, Самарадан да җаның теләгән сортларын ташыйлар. Эчемлекләргә килгәндә, олылар лимонлы салкын чәйне, сыраны һәм ипи квасын өстенрәк күрәләр. Табиблар гади суны артык күп эчәргә киңәш итмиләр, йөрәккә һәм бөерләргә көч килә диләр.

Ә инде бу кызуда нинди чаралар күрергә мөмкин булуына килсәк, анысын кем ничек булдыра ала инде.

Валентина Михайловна, 47 яшь:

- Мин отпускада. Идәнгә бастырып куя торган җилләткеч коткара - иртәдән кичкә кадәр әйләнә. Моннан салкын тияргә дә мөмкин дип ишеттем әле.

Гүзәл, хезмәткәр:

- Иртән бер, төш чорында һәм кичен икешәр тапкыр коенам...

В., төзүче:

-Тапкансыз сорау. Күрмисезмени, суга төшкән тычкан шикелле бит.

... Адәм баласына гомергә ярап булмый шул инде. Гел нәрсә дә булса җитми безгә. Җәен кызуга, кышын салкынга түзмибез...

**Т.НАЗАРОВА.**

### БАЛАЛАРНЫҢ ҖӘЙГЕ ЯЛЫ



## "Көньяк кояшы сихәтле икән",-

диделәр районнан Анапага барып, ял итеп кайткан балалар. Бу көннәрдә аларның өчесе - 4нче мәктәп укучылары Рөстәм Хәсәнов, Илнар Мусин, Марат Юнысов редакциядә булып киттеләр.

- 45 кешедән торган төркемебез исән - сау көньякны әйләнеп кайтты. Тәэсирләребез - сөйләп бетермәслек. Без Анапа шәһәре читендәге ял базасында өйчекләрдә яшәдек. Безнең белән бергә Татарстанның Әлмәт шәһәреннән килгән балалар тордылар. Моннан тыш, биредә Казан, Зәй, Яр Чаллы, Болгар шәһәрләреннән якташларыбызны да күрергә мөмкин иде. Анапада Татарстаннан 600 бала ял итә, диделәр... Алар белән дуслаштык, адреслар алыштык.

Балалар яшәү - ял рәвешеннән канәгать калганнар. Көндәлек режимга 1 - 2 сәгатьлек эш кертелгән булганлыктан, алар шәфталу, виноград җыю белән шөгыльләнгәннәр. Биредәге төсле зур - зур виноград плантацияләре аларда гаҗәпләнү һәм соклану уяткан.

- Без әле Новороссийск шәһәрендә экскурсиядә дә булдык,- диләр балалар бер - берләрен бүлеп.

Ә һәр көнне төшке аштан соң 3 сәгать вакытларын диңгездә үткәргәннәр. Кара диңгез дулкыннарында тибрәнү, аның комында кызыну, көньяк кояшыннан ял һәм сихәт алу алар өчен бик тә күңелле, истәлекле булган.

- Сезгә киләсе елда да шундый ял тәкъдим итсәләр?...

-...Һичшиксез ризалашыр идек!- диделәр егетләр бертавыштан.

Ә саубуллашканда шундый ял мөмкинлеген оештыручылар - район хакимиятенең мәдәният һәм мәгариф бүлекләре җитәкчеләренә, ГИБДД инспекторы Ф.Н.Низаметдиновка чын күңелдән рәхмәт белдерүебезне сорадылар.

Балалар соравын үтәми буламы соң?!


Әнә бит алар ничек ныгып, каралып, шат күңел белән ял итеп кайтканнар диңгез буеннан!

**С.НУРУЛЛИНА.**

## "ЗАРЕЧНЫЙ"ДА - ИКЕНЧЕ СМЕНА

3 августтан "Заречный" лагеренда икенче смена башланды.

Беренче сменада ял иткән 128 бала бик канәгать булып таралышкан иделәр. Икенче сменада ял итәргә теләүчеләр дә аз булмады - хәзер 125 укучы җәйге хозурлыкка куанып ял итәләр, көч җыялар, яшьтәшләре белән аралашу шатлыгы кичерәләр.




Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ
фотоэтюды.

## Матбугатка язылуда "каникул" юк

Вакытлы матбугат басмаларына билгеле бер айларда гына язылa торган заманнар артта калды. Хәзер бу кампания "каникул"сыз алып барыла һәм район почта элемтәсе идарәсенең махсус операторы сезгә ел тәүлеге диярлек хезмәт күрсәтә. Россиядә чыга торган кайбер газета һәм журналларга 1999 елның беренче яртыеллыгына бүген үк язылып куярга мөмкин. 1998 елның икенче яртыеллыгына булган бәяләр буенча үткәрелүче льготалы ул язылу 31нче августка кадәр барачак. Дөрес, андый ният белән килүчеләр күп түгел әле, ә менә агымдагы елның калган айларына газет - журнал яздырырга теләүчеләр бар. "Казанские ведомости" әбунәчеләр арасында Европаның 8 башкаласына путевка, 3 телефон, 10 тузан суырткыч уйнатырга вәгъдә итсә дә, почтага килүчеләр күбрәк "Труд"ның калын кушымтасын яздыруны кулай күрәләр, "Вечерняя Казань", "Юлдаш" һәм, билгеле инде, "Дуслык"ны сорыйлар.

Район газетасының гомуми тиражы хәзер 10380 данәдән артып китте, ә аны укучылар берничә тапкыр күбрәк, билгеле. Арада газетаны ярты гасырдан күбрәк алдыручылар да бар! Яңа Әмзәдән Гомәр ага Җамалиев "Дуслык"ны 54 ел укый икән инде! Тельман, Биләр, Октябрь районнары чагында да алдырган, хәзер дә "Дуслык"сыз тормый. Тугры укучыбызга рәхмәтебез зур!

Россия газеталары арасында быелның икенче яртыеллыгында "Спид - инфо" беренчелекне тотса, Татарстанда чыга торганнарыннан "Республика Татарстан"ны хуп күрәләр.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Кизләү авылында гомер итүче **Асия Зариф кызы Курамшинага** 7 августта - 60 яшь.

Кадерле әниебезне туган көне белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Киң күңелле, сабыр холыклы, олы йөрәкле әниебезгә ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, күп еллар безне сөендереп, бәхетле яшәвен телибез.

Зәңгәр күкләр, матур йолдыз белән,
Исле гөлләр белән җир ямьле.
Йолдызлардай якты, гөлдәй гүзәл,
Синең белән туган йорт ямьле.
Чәчләреңә, әни, чал керсә дә,
Син бит безнең йөрәк түрендә.
Озак яшә, кадерлебез, авырмыйча,
Син - дөньяда безгә бер генә.

**Киленең Мәрьям, улың Мансур, оныкларың Динә һәм Марат.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**УАЗ - 452 (фургон) һәм ЛУАЗ - 969**. Тел.: 5-21-54.

***

**Әфган поселогында фундаменты белән участок.** Тел.: 5-46-64.

***

**Дүрт бозаулаган яхшы сыер.** Егоркинода Бикинеевага мөрәҗәгать итәргә.

***

**10 х 9лы бура, бәясе килешү буенча.** Тел.: 4-13-78, 2-25-16.

***

**1982 елгы "Москвич - 2140", 5500 сум.** Тел.: 5-20-04.

***

**1992 елның декабрендә чыккан ВАЗ - 21061.** Андреевкада А.Н.Даниловка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 39-2-53.

***

**Красноармейская ур., 59 - 3 адресы буенча йорт яны участоклы ике бүлмәле фатир.** Тел.: 5-11-74.

***

**Иске заправка янында чанада гараж.** Тел.: 2-13-14, кичке 5 тән соң.

***

**1986 елгы ВАЗ - 21063.** Адрес: Кормыш пос., Көнчыгыш ур., 5, теләсә кайчан.

***

**ЖКХ чистарту корылмалары ягында капиталь гараж, яңа "Урал" мотоциклы.** Тел.: 5-15-27.

***

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә ике бүлмәле телефонлы фатир, кулланылышта булган стенка, кыйммәт түгел.** Адрес: К.Маркс ур., 27 - 7, тел.: 2-29-15.

***

**ҺӘРВАКЫТ! АРЗАН!**

**Италия, Германия, Польшада эшләнгән кухня гарнитурлары, стенкалар, йокы бүлмәсе мебеле, җыелма өстәлләр, урындыклары белән өстәлләр, йомшак җиһаз сатыла, китереп һәм җыеп бирелә.** Тел.: 5-22-20. Б - 97 № 004778 лицензия.

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Яр Чаллы шәһәрендәге 4 бүлмәле фатирны - Нурлатта өстәмә түләп 2 бүлмәлегә.**

Тел.: 5-39-42, кичке 6 дан соң.

***Димитровград шәһәренең Промышленная урамындагы (89нчы йорт) "Согдиана" фирмасы:***

**- мең данәсен - 810, китереп биргәндә 850 сумнан силикат кирпеч,**

**- данәсен 3 сум 20 тиеннән (3 сум 90 тиен) керамзит блоклар**

**тәкъдим итә.**

Тел.: 3-04-96, 3-27-23.

## ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

***"Нурлат АТПсы" АҖнә ашыгыч төстә 4 - 5 разрядлы токарь, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы кирәк ( түләү - вакыт исәбеннән - премиаль).***

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Геннадий Аркадьевич Беляков исеменә документлар белән сумка табучының бүләк бәрабәренә К.Маркс ур., 9 - 2 адресы буенча кайтарып бирүен сорыйбыз.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. **3217.**